**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 февраль № 105

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 7 август, 572 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 7 август, 572 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 21 декабрь, 962 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә, преамбуласында һәм 1 нче пунктында «2015 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү эшләрен башкару белән бәйле финанс ягыннан тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр бирү тәртибендә:

исемдә һәм 1 нче пунктта «2015 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче пунктта «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» сүзләрен «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында» сүзләренә алмаштырырга;

10 нчы пунктта «2016 елның 1 февраленә кадәр» сүзләрен «хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\105.docx